**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

04 03 2022 ел Яр Чаллы № 586

«2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасын раслау турында

Тукай муниципаль районы халкы арасында наркотиклар куллануны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча эшне оештыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 елның 8 январендагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы, «Наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022-2024 елларгаТукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасын расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 4 мартындагы 586 номерлы карарына кушымта

# «2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасы

**Яр Чаллы – 2022**

**ЭЧТӘЛЕГЕ**

1. Программа паспорты

2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

3. Программаның максаты

4. Прөграмманың бурычлары

5. Программаны тормышка ашыру вакыты

6. Программаны финанс белән тәэмин итү

7. Гамәлгә ашыру еллары буенча планлы күрсәткечләрне расшифровкалау белән программаның максатчан күрсәткечләре исемлеге

8. Көтелгән нәтиҗәләр

9. 2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау буенча район комплекслы программасын гамәлгә ашыру чаралары

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасы (алга таба - Программа) |
| **Программаны эшләү өчен нигез** | Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы;<br>«Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2014 елның 23 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы |
| **Программаның дәүләт заказчысы** | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны эшләүче** | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге һәм наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча район комиссиясе |
| **Программаны төп башкаручылар** | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе;<br>Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>«Үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (наркология кабинеты) (килешү буенча);<br>Якты юл» («Светлый путь») район газетасы (килешү буенча);<br>Яр Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Тукай муниципаль районы буенча филиалы (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай муниципаль районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр (килешү буенча) |
| **Программаның төп максаты** | Тукай муниципаль районы территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору, наркотик һәм психотроп матдәләр куллану һәм тарату белән бәйле хокук бозуларны профилактикалау |

| | |
|---|---|
| **ограмманың урычлары һәм мөһим күрсәткечләре** | 1. Наркотикларга каршы профилактик эшчәнлеккә мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль тәэмин итү, хокук саклау системасы учреждениеләрен һ.б. җәлеп итү.<br>2. Наркотикларга бәйле кешеләргә дәвалау һәм реабилитация ярдәме, туганнары һәм наркотикларга бәйле кешеләр белән социаль-психологик эш системасын камилләштерү.<br>3. Наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча хокук саклау органнарының хезмәттәшлеге системасын камилләштерү.<br>4. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып бару һәм наркотиклар куллануга тискәре караш булдыру.<br>5. Балаларны һәм яшьләрне төрле түгәрәкләргә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү.<br>6. Бай рухи-әхлакый, физик яктан алга киткән шәхес формалаштыру |
| **Муниципаль программаның максатчан күрсәткечләре исемлеге** | - Күрсәтелгән категориянең гомуми санында Программа һәм профилактик чараларга җәлеп ителгән 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләрнең чагыштырма зурлыгы;<br>- Диспансер һәм профилактик исәптә торучы затлар саны;<br>- Сәламәт яшәү рәвешен алып баруга һәм наркотиклар һәм психоактив матдәләр куллануга тискәре мөнәсәбәткә юнәлдерелгән чаралар саны |
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | Программаны финанслауның гомуми күләме районның җирле бюджетыннан 907 500 сум тәшкил итә.<br>шул исәптән, еллар буенча:<br>2022 ел - 302 500 сум;<br>2023 ел - 302 500 сум;<br>2024 ел - 302 500 сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| **Программаны тормышка ашыру вакыты** | 2022-2024 еллар. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән һәм соңгы нәтиҗәләре** | Балалар һәм яшьләр тарафыннан социаль үз-үзеңне тоту күнекмәләрен алу, психоактив матдәләрне куллануны мотивацияләү дәрәҗәсен киметү;<br>Һөнәри юнәлеш бирү, физик культура белән шөгыльләнү, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен шартлар тудыру;<br>Район халкын спорт секцияләренә һәм техник берләшмәләргә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешенә тарту;<br>Җинаятьчелек дәрәҗәсе кимү;<br>Педагогларның балалар, шул исәптән хәвеф төркемендәгеләр белән, эшләүгә психологик-педагогик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;<br>Наркомания проблемасына җәмәгатьчелек һәм төрле оешмаларның игътибарын җәлеп итү |
| **Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту** | Программаны тормышка ашыруны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр |

| | |
|---|---|
| | һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе һәм наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча район комиссиясе контрольдә тота. |

## I. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Соңгы елларда Тукай районында наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча максатчан эш Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Указы, «Наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ЗРТ номерлы ТР Законы һәм 2012 елның 27 декабрендәге 18/1 номерлы «2013-2017 елларга Тукай муниципаль районында наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча район комплекслы программасы» нигезендә башкарылды.

Район программасының төп максаты – Тукай муниципаль районы территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору, наркотик һәм психотроп матдәләр куллану һәм тарату белән бәйле хокук бозуларны профилактикалау.

Әлеге программа нигезендә:

1. Халыкны наркотиклаштыруга каршы тору чараларының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән берничә норматив-хокукый акт эшләнде.
2. Наркотикларга ихтыяҗны кисәтү һәм киметү, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча эш алып барылды.
3. Тематик акцияләр, концертлар, спорт чаралары үткәрелде; массакүләм мәгълүмат чараларында күп санлы материаллар басылып чыкты.
4. Наркотик чараларның законсыз әйләнешен кисәтү һәм хокук саклау органнары бүлекчәләренең матди-техник базасын ныгытуга юнәлдерелгән чаралар тормышка ашырылды.
5. Наркотик чаралар, психотроп матдәләр куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча район органнары һәм учреждениеләре эшен гомуми координацияләүне муниципаль наркотикларга каршы комиссия гамәлгә ашыра. Квартал саен комиссия утырышлары үткәрелә.

Кабул ителгән гамәлләргә карамастан, наркомания проблемасы халыкның сәламәтлегенә һәм милли куркынычсызлыкка глобаль куркыныч рәвешендә беренче урыннарда тора. Наркомания яшьләр арасында тарала.

Тукай районы үзәк хастаханәсе мәгълүматлары буенча 2019-2021 еллар чорында наркомания белән авыручылар санының динамикасы түбәндәгечә:

Статистика буенча наркотикларга бәйле затлар диспансеры исәбендә тора:

2019 елда – 66 кеше («Д» исәпкә алу – 32, «П» исәпкә алу – 34, бер ел эчендә барлыгы алынган («Д» исәпкә алу – 6, «П» исәпкә алу – 9 кеше).

2020 елда 69 кеше («Д» исәпкә алу – 42, «П» исәпкә алу – 27, бер ел эчендә барлыгы алынган («Д» исәпкә алу – 2, «П» исәпкә алу – 12 кеше).

2021 елда 69 кеше («Д» исәпкә алу – 27, «П» исәпкә алу – 42, бер ел эчендә барлыгы алынган («Д» исәпкә алу – 4, «П» исәпкә алу – 13 кеше).

Гомумән алганда, наркотикларга бәйлелек белән авыру буенча үсешнең стабильләшүе күзәтелә. Наркотикларга бәйлелектән җәфа чигүчеләр саны шактый кимеде. Кызыксыну максатыннан алга таба кулланмыйча наркотик матдәләр кулланучылар саны элеккеге дәрәҗәдә саклана. Тукай районы халкы арасында наркотик матдәләрне беренчел куллану проблемасы, беренче чиратта, Яр Чаллы кебек эре торак пунктка якын булу белән бәйле.

2021 ел өчен Тукай районы халкы арасында наркотик матдәләр һәм аны кулланудан психозлар нәтиҗәсендә наркология диспансерына госпитализацияләрнең булмавы билгеләп үтелә. Наркологта исәптә торучы затлар турында мәгълүмат авыл фельдшер акушерлык пунктларыннан һәм участок полиция хезмәткәрләреннән даими рәвештә килә.

Наркотикларга бәйлелек авыруын булдырмау буенча, шулай ук наркотикларга бәйлелектән шифа чигүче затлар арасында профилактик эшләр алып барыла:

- фельдшер акушерлык пунктларында наркотиклардан файдалануның зарары турында плакатлар эленгән, наркотик матдәләрдән файдалануның зыяны турында бюллетеньнәр бар. Пплакатлар районның барлык фельдшер акушерлык пунктларында да бар;

- мәктәпләрдә өлкән сыйныф укучылары өчен алкоголь, тәмәке һәм наркотикларның зыяны турында лекцияләр үткәрелә. Районның иң зур торак пунктларында өлкән сыйныф укучылары арасында (346 кеше) наркотик матдәләр куллануны ачыклау буенча тест үткәрелде (2018 елның октябрь - ноябрь айларында);

- район газетасында наркотик матдәләр, тәмәке тарту һәм алкоголь куллануның зыяны турында мәкаләләр басылды;

- Тукай районы халкы арасында вакытлы медицина тикшерүләре, машина йөртү таныклыгын алу, эшкә урнашканда психиатр-нарколог кабинетында карау узганда алкоголь, наркотиклар һәм тәмәке тартуның зыяны турында профилактик әңгәмәләр үткәрелә;

- балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе һәм муниципаль ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумы составында имин булмаган гаиләләргә ай саен өйгә чыгып йөрүләр гамәлгә ашырыла;

- наркологта исәптә торучы кешеләргә даими рәвештә наркотик матдәләр куллануга тест үткәрелә, бу алга таба наркотик препаратларны куллануны тоткарлаучы һәм алга таба ремиссия чоры җитүгә фактор булып тора.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең шәхси составы тарафыннан районда яшәүчеләр тарафыннан наркотик һәм психотроп матдәләр куллану фактларын профилактикалауга һәм булдырмауга юнәлдерелгән профилактик һәм оператив - эзләү чаралары, шулай ук район торак пунктларында наркопритоннар барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар үткәрелә.

Районда наркотиклар белән ситуацияне контрольдә тотуны тәэмин итү һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьчелеккә каршы көрәш өлкәсендә бурычларны уңышлы хәл итү максатыннан, Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге тарафыннан район торак пунктларында наркотик кулланучыларны һәм законсыз таратучыларны ачыклау буенча оператив-профилактик чаралар үткәрелә.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге хезмәт күрсәткән территориядә барлыгы 19 наркотиклар белән бәйле җинаять теркәлгән (АППГ-20), 10 җинаять тикшерелгән (АППГ-11), 6 туктатылган (АППГ-9), җинаять ачылышы 62,5% тәшкил иткән (АППГ-55 %).

Барлыгы (шартлы бүлеп бирелгәнне исәпкә алмыйча) 13 наркотик җинаяте (АППГ - 11), наркотиклар сату белән бәйле 4 җинаять теркәлгән (АППГ-2), тикшерү - 100 %.

«Мәк-2021» операциясе барышында бүлекнең шәхси составы тарафыннан Тукай районы территориясендә кыргый киндерне юк итүнең 3 очрагы теркәлде. Йолкып ыргыту, чабу, авыр авыл хуҗалыгы техникасы белән сөрү юлы белән барлыгы 81 куак юк ителде, РФ КоАП 6.8 ст. буенча 1 административ хокук бозу ачыкланды.

Район территориясендә наркотик матдәләр куллану һәм сату белән шөгыльләнүче затларны ачыклау максатыннан, бүлек хезмәткәрләре тарафыннан даими рәвештә наркотиклар белән бәйле ситуациягә мониторинг үткәрелә, шул ук вакытта Тукай районы үзәк хастаханәсе һәм Яр Чаллы шәһәре наркология диспансеры мәгълүматлары кулланыла. Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге Яр Чаллы шәһәре наркология диспансеры белән берлектә ай саен наркотикларны табиб билгеләвеннән башка куллану фактын тикшерү өчен китерелә торган затлар буенча тикшерүләр үткәрә. 2021 ел нәтиҗәләре буенча 44 наркотик исереклеккә тикшерү үткәрелгән, аларның 26сы – Тукай районында, 18е - башка район һәм шәһәрләрдә яшәүчеләр.

2021 елда район территориясендә наркотик матдәләрне артык куллану белән бәйле үлем очраклары теркәлмәгән.

Ай саен, наркология кабинетында исәпкә куелган затларны ачыклау һәм алга таба әлеге затлар белән профилактик чаралар үткәрү максаты белән, әлеге өлештә Тукай районы үзәк хастаханәсе наркология кабинеты, Яр Чаллы шәһәре наркология диспансеры белән чагыштыру үткәрелә.

Район мәктәпләренең педагогик составы белән укучыларга хокукый белем бирү мәсьәләләрендә үзара хезмәттәшлек алып барыла. Балигъ булмаганнар эшләре бүлеге хезмәткәрләре укучыларга һәм аларның ата-аналарына наркотик матдәләр куллануның зарарлы нәтиҗәләре, шулай ук әлеге өлкәдәге җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгы турында даими рәвештә мәгълүмат җиткерәләр.

«Мәк» оператив-профилактик чарасы, шулай ук «Үлем белән кайда сатуларын хәбәр ит!» акиясе турында район массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән «Якты юл» («Светлый путь») район газетасында, шулай ук Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең интернет - порталында урнаштырылган.

Наркотикларга бәйле кешеләрне реабилитацияләү һәм ресоциализацияләү буенча хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек итү, аларның эшчәнлеге турында оператив мәгълүмат алу, шулай ук хокук бозуларны кисәтү, реабилитантларны законсыз тоту фактларын ачыклау, эзләнүдә булган затларны ачыклау максатыннан, Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан тернәкләндерү үзәкләре буенча тиешле эш алып барыла.

Тернәкләндерү үзәкләрендә хокук бозуларны кисәтү, реабилитантларны законсыз тоту фактларын ачыклау, эзләнүдә булган затларны ачыклау максатыннан, ай саен профилактик чаралар үткәрелә.

Хисап чорында үзәк хезмәткәрләре тарафыннан гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланмады.

Барлыкка килгән хәлне анализлаудан, аның якын киләчәккә үсешен фаразлаудан чыгып, социаль, медицина, профилактик, хокукый һәм оештыру характерындагы координацияләнгән чаралар комплексын күздә тоткан «2022-2023 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау буенча комплекслы район программасы»н тормышка ашыру зарурлыгы күзгә күренеп тора.

Наркоманиягә каршы көрәш проблемасын хәл итү бер финанс елы чикләрендә генә мөмкин түгел, чөнки озак вакытлы социаль характердагы күп санлы чаралар үткәрү күздә тотыла: наркоманиягә каршы көрәшнең яңа методикаларын һәм технологияләрен эшләү, наркомания белән авыручы затларны дәвалау һәм тернәкләндерү. Программа өч еллык чорга исәпләнгән, аны озайтырга мөмкин.

Әлеге программа төп башкаручылар тәкъдимнәренә таянып әзерләнгән. Программа ведомствоара характерда, ул анда катнашучыларның гамәлләрен алга таба координацияләүгә юнәлдерелгән, наркотик чараларны, психотроп матдәләрне куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы бердәм стратегия үткәрүгә, аны башкаручыларның җаваплылыгын күтәрүгә ярдәм итәргә тиеш.

## II. Программаның максаты

Тукай муниципаль районы территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору, наркотик һәм психотроп матдәләр куллану һәм тарату белән бәйле хокук бозуларны профилактикалау.

## III. Программаның бурычлары

1. Наркотикларга каршы профилактик эшчәнлеккә мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль тәэмин итү, хокук саклау системасы учреждениеләрен һ.б. җәлеп итү.
2. Наркотикларга бәйле кешеләрне дәвалау һәм тернәкләндерү системасын камилләштерү, туганнары һәм наркотикларга бәйле кешеләр белән социаль-психологик эш алып бару.
3. Хокук саклау органнарының наркотик чараларны куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча хезмәттәшлеге системасын камилләштерү.
4. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып бару һәм наркотиклар куллануга тискәре караш булдыру.

5. Балаларны һәм яшьләрне төрле түгәрәкләргә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү.

6. Бай рухи-әхлакый, физик яктан алга киткән шәхес формалаштыру.

7. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.

## IV. Программаны тормышка ашыру вакыты

Программа 2022-2024 елларда тормышка ашырыла.

## V. Программаны финанс белән тәэмин итү

Районның җирле бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 2 557 500 сум тәшкил итә.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

## VI. Гамәлгә ашыру еллары буенча планлы күрсәткечләрне расшифровкалау белән программаның максатчан күрсәткечләре исемлеге

| № ,,,,,, | Критерийларның исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Күрсәтелгән категориянең гомуми санында Программа һәм профилактик чараларга җәлеп ителгән 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләрнең чагыштырма зурлыгы | % | 35 | 37 | 40 |
| 2 | Диспансер һәм профилактик исәптә торучы затлар саны | кеше | 69 | 68 | 67 |
| 3 | Сәламәт яшәү рәвешен алып баруга һәм наркотиклар һәм психоактив матдәләр куллануга тискәре мөнәсәбәткә юнәлдерелгән чаралар саны | берәмлек | 170 | 170 | 170 |

## VII. Фаразланган нәтиҗәләр

1. Балалар һәм яшьләр тарафыннан социаль үз-үзеңне тоту күнекмәләрен алу, психоактив матдәләр куллануны мотивацияләү дәрәҗәсен киметү;
2. Наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе.
3. Педагогларның балалар, шул исәптән хавеф төркемендәгеләр белән, эшләүгә психологик-педагогик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү.
4. Наркомания проблемасына җәмәгатьчелек һәм төрле оешмаларның игътибарын җәлеп итү.
5. Һөнәри юнәлеш бирү, физик культура белән шөгыльләнү, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру сыйфатын арттыру.

«2022 - 2024 елларга Тукай муни... районында наркоманияне профилактика... программасына кушымта

**«2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплексды программасы буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын еллар буенча бүлү (сумнарда) | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 | | |
| 1. | «Здоровый я- здоровая страна!» рәсем конкурсы | 2000 | 2000 | 2000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 2. | Тематик әңгәмә: «Мин тормышта сайлыйм», «Басып торам юллар чатында», «Сәламәт булу серләре» | 1500 | 1500 | 1500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 3. | «Сәламәт булыйк» рәсем конкурсы | 2000 | 2000 | 2000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 4. | «Верь сам в себя наперекор Вселенной!», «Психотропные вещества», «Осторожно человек-помни 21век!» яшүсмерләр өчен нарколог һәм психиатр лекциясе конкурсы | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 5. | Яшьләр белән очрашу «Яшьләр һәм наркомания» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 6. | «Скажи жизни ДА!» түгәрәк өстәл | 3 500 | 3 500 | 3 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 7. | «Правонарушение и ответственность» участковыйлары белән очрашу | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 8. | «Үзеңне наркотикларга бәйләмә» чарасы | 1 000 | 1000 | 1000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 9. | Түгәрәк өстәл «Минем яшисем килә» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 10. | Түгәрәк өстәл «Жизнь без наркотиков» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 11. | «Наркотикам нет!» рәсемнәр, плакатлар конкурсы | 7000 | 7000 | 7000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 12. | «Надо жить честно!» коррупциягә каршы балалар рәсемнәре һәм плакатлары конкурсы | 7000 | 7000 | 7000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» | «Мәктәптән тыш эшләр |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | МБББУ | үзәге» М... |
| 13. | «Созвездие Йолдызлык» сәнгать фестивале | 75 000 | 75 000 | 75 000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 14. | «Без бергә» Республика балалар иҗаты фестивалендә катнашу | 45 000 | 45 000 | 45 000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 15. | Гомуми белем бирү оешмаларының хокук бозуларны профилактикалау отрядлары арасында конкурс | 6000 | 6000 | 6000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 16. | «Лучший уголок профилактики по наркомании среди учащихся» конкурсы | 5000 | 5000 | 5000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 17. | Спорт ярышларын оештыру һәм уздыру:<br>- Егетләр һәм кызлар арасында бадминтон буенча район беренчелеге һәм чемпионаты,<br>- Яшүсмерләр арасында футбол буенча «Күн туп» район беренчелеге,<br>- Авыл җирлекләре, район оешмалары һәм предприятиеләренең ир-ат командалары арасында футбол буенча район чемпионаты,<br>- Авыл җирлекләре, предприятиеләр һәм оешмалар командалары арасында волейбол буенча чемпионат | 50000 | 50000 | 50000 | Тукай муниципаль районы «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 18. | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ укучылары арасында спорт ярышлары үткәрү:<br>- егетләр һәм кызлар арасында Бөтенроссия наркотикларга каршы акциягә багышланган йөзү буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>«Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне»нә багышланган бадминтон буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- чаңгы ярышлары буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- кикбоксинг буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- егетләр һәм кызлар арасында спорт (ирекле) көрәш буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- егетләр арасында көрәш буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- Суда бәйрәм: «Весёлые старты!»;<br>- егетләр һәм кызлар арасында өстәл теннисы буенча спорт | 43000 | 43000 | 43000 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәктәбенең ачык беренчелеге;<br>- Гаилә көненә багышланган спорт чарасы;<br>- Олимпия көненә багышланган спорт-күңел ачу чарасы | | | | | |
| 19. | Авыл фельдшерлары арасында «Профилактика наркологических заболевании на селе» темасына семинарлар үткәрү | | | | финанслау таләп ителми | Тукай районы үзәк хастаханәсе ДАССУ |
| 20. | «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» темасына профилактика субъектлары белән оештырылган чараларда катнашу | | | | финанслау таләп ителми | Тукай районы үзәк хастаханәсе ДАССУ |
| 21. | Наркология кабинетында исәптә торучы авырулар белән дәвалау һәм тернәкләндерү чаралары үткәрү | | | | финанслау таләп ителми | Тукай районы үзәк хастаханәсе ДАССУ |
| 22. | Районның һәр торак пунктында « Нет наркотикам!» дигән темага санитар бюллетеньнәр чыгару, шулай ук күрсәтмә агитация чараларын тарату | | | | финанслау таләп ителми | Тукай районы үзәк хастаханәсе ДАССУ |
| 23. | Районның өлкән сыйныф укучылары арасында наркотик матдәләр куллану предметына бәвелгә скриниг тест үткәрү | | 50000 | 50000 | Мәгариф идарәсе | Тукай районы үзәк хастаханәсе ДАССУ |
| 24. | Районның гомуми белем бирү оешмаларында наркотикларга каршы профилактик чаралар үткәрү: акцияләр, квестлар, тематик чаралар, мастер-класслар һ.б. | 50000 | | | Мәгариф идарәсе | Мәгариф идарәсе |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **302500** | **302500** | **302500** | | |